ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02 ноябрь 2020 ел** **№ 3**

2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Нарат-Асты авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатькә ТР, Сарман муниципаль районы, Нарат-Асты авылы, Нарат Асты ур., 21а йорт адресы буенча урнашкан Нарат-Асты авылы медпункты бинасына 2021 елда Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Нарат-Асты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме:

1) Нарат-Асты авылы урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
2) Нарат-Асты авылы җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Нарат-Асты авылы өчен газонокосилка (Тремер) сатып алу;

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Чукмарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Хадиуллин